КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 декабрь г.Казань № 1174

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче карары белән расланган Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипен-

дияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 28 март, 193 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Гаилә составына түбәндәгеләр керә:

ир белән хатын, шул исәптән аерым яшәүче ир белән хатын, һәм аларның балигъ булмаган (шул исәптән уллыкка, кызлыкка алынган) балалары, аларның уртак балалары булмаган, иренә (хатынына) карата алимент йөкләмәләре барлыкка килгән балигъ булмаган балалардан тыш;

никахлы булмаган ата яки ана һәм аның балигъ булмаган (шул исәптән уллыкка, кызлыкка алынган) балалары, атага яки анага карата алимент йөкләмәләре барлыкка килгән балигъ булмаган балалардан тыш;

никахлашмаган, даими яшәү урыны буенча яки вакытлыча тору урыны буенча бергә яшәүче ата-аналар (никахларын өзгән ата-аналардан тыш) һәм аларның балигъ булмаган (шул исәптән уллыкка, кызлыкка алынган) балалары, аларның уртак балалары булмаган, ата-аналарга карата алимент йөкләмәләре барлыкка килгән балигъ булмаган балалардан тыш.

Опекада (попечительлектә) булган балаларны карап тоту өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә акча түләнмәгән, опекада (попечительлектә) булган балага айлык пособие билгеләү максатларында гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләгәндә аның ата-аналары (атасы йә анасы), яшәү (тору) урынына карамастан аның балигъ булмаган ир һәм кыз туганнары һәм бала үзе исәпкә алына.»;

1.3 нче пунктның бишенче абзацында «шулай ук» сүзләреннән соң – «тикшерү органнары яки суд карары нигезендә суд-медицина экспертизасы үтүгә бәйле рәвештә,» сүзләрен, «суд карары белән мәҗбүри дәваланудагы затлар» сүзләреннән соң «, шулай ук эчке эшләр органнары, суд приставлары-башкаручылары тарафыннан эзләүдә булган затлар;» сүзләрен өстәргә;

2.1 нче пунктның «к» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«I төркем инвалидны, дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ булган йә 80 яшькә җиткән өлкәннәрне карауны гамәлгә ашыручы, хезмәткә сәләтле эшләмәүче затларга айлык компенсация түләүләре;

18 яшькә кадәрге инвалид баланы яки балачактан I төркем инвалидны карауны гамәлгә ашыручы, хезмәткә сәләтле эшләмәүче затларга айлык түләүләр;»;

2.2 нче пунктның «а» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«беренче бала тууга (уллыкка, кызлыкка алуга) бәйле рәвештә, айлык түләү;»;

3.1 нче пунктта:

бишенче һәм алтынчы абзацлар үз көчен югалткан дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«бала туганда авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган түләү.»;

5.9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.9. Эш бирүче белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы, тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче гаилә әгъзаларының керемнәре түбәндәгечә билгеләнә торган шартлы айлык эш хакыннан чыгып исәпләнә:

тулы булмаган эш атнасы булган очракта, фактта исәпләнгән уртача көнлек хезмәт хакы күләме (моның өчен әлеге айда фактта эшләнгән хезмәт хакы фактта эшләнгән көннәр санына бүленә) айның керем исәпләнә торган эш көннәре санына тапкырлана;

тулы булмаган эш көне булган очракта, фактта эшләнгән вакыт өчен исәпләнгән хезмәт хакы суммасы фактта эшләнгән сәгатьләр санына бүленә һәм хезмәткәрләрнең тиешле категориясе өчен хезмәт законнары белән билгеләнгән айга эш вакыты нормасына тапкырлана.

Эш бирүче белән хезмәт һәм аларга тиңләштерелгән мөнәсәбәтләрдә торучы һәм хезмәт хакын сакламыйча ялда булган (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 128 статьясындагы икенче өлешенең икенче – җиденче абзацларында күрсәтелгән хезмәт хакын сакламыйча ял бирү очракларыннан тыш) гаилә әгъзаларының керемнәре мондый ял чорында хезмәткәрнең тариф ставкасының (окладының) өчтән ике өлеше зурлыгы буенча шартлы хезмәт хакы күләменнән чыгып исәпләнә.»;

5.14 нче пунктның беренче абзацы татар телендә үзгәрешсез кала;

5.15 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.15. Әгәр эшкә сәләтле гражданның (гомуми белем бирү оешмасында яисә һөнәри белем бирү оешмасында яки югары белем бирүче мәгариф оешмасында көндезге форма буенча белем алучы 18 яшькә кадәрге эшкә сәләтле заттан тыш) кереме балага айлык пособие билгеләү турында гариза биргән көндә эшкә сәләтле халыкның яшәү минимумы зурлыгы билгеләнгән Татарстан Республикасында кулланучылар кәрзиненә кертелә торган азык-төлек һәм хезмәт күрсәтүләр бәясе суммасыннан кимрәк булса, гражданның кереме сыйфатында балага айлык пособие билгеләү турында гариза биргән көндә эшкә сәләтле халыкның яшәү минимумы зурлыгы билгеләнгән Татарстан Республикасында кулланучылар кәрзиненә кертелә торган азык-төлек һәм хезмәт күрсәтүләр бәясе суммасы исәпкә алына.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин